,
.


# Авторы публикации:

**Гиззатуллина Гульназ Ильфатовна,**

**Садикова Разиля Расуловна**

**воспитатели МБДОУ детский сад №34**

**«Радуга» комбинированного вида**

**Елабужского муниципального района РТ**


## Название работы: «Литературно-музыкальный вечер»

## Тема: «Тукай безнең йөрәкләрдә»

### «Тукай безнең йөрәкләрдә»
### (мәктәпкә әзерлек төркеме балалар өчен Г. Тукайның иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

**Максат:** Балаларны татар халкының бөек шагыйре Г.Тукай турындагы белемнәрен киңәйтүне дәвам иттерү; шагыйребезнең әкиятләре, шигырьләре һәм җыр-бию аша кешелеклелек, шәфкатьлелек сыйфатлары, туган телебезгә олы ихтирам хисе тәрбияләү; ялганламаска, җәнлекләрне, табигатьне яратырга өйрәтү; аларны рәнҗетергә ярамавын сабыйлар күңеленә сеңдерү.

**Катнашалар:**
Алып баручы
Шүрәле
Акбай
Су анасы
Балалар.

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Түрдә Тукай портреты, чәчәкләр, әкиятләрдән, шигырьләрдән иллюстрацияләр. З. Яруллинның «Тукай маршы» астында балалар залга керәләр

**Алып баручы**: Язның иң матур бер көнендә, карлар эреп, бозлар агып киткәч, агач һәм куакларда хуш исле бөреләр уянган чакта яраткан шагыйребез Габдулла Тукай туган. Һәр елны бакчабызда сөекле шагыйребез иҗатына багышлап әдәби кичәләр уздырыла.Бүген дә без бөек шагыйребез Габдулла Тукайны искә алырга ,аның туган көнен бәйрәм итәргә җыелдык.Тукай халкыбызның сөекле шагыйре.Аның туган көнен бөтен татар халкы билгеләп үтә.Тукайның шигырьләре ,әкиятләре кечкенәдән белем алырга ,эш сөяргә ,табигатьне сакларга, туган җиребезне ,туган телебезне яратырга чакыра.Без дә бүген шул шигырьләрне, әкиятләрне искә төшерербез.

**Диләрә:**
Татарстан – Тукай иле,
Татарстан – безнең ил.
Бүген бездә – Тукай көне,
Кил бәйрәмгә, дустым, кил.

**Диләә:**
Тукай белән сөйләшеп ал,
Тукайдан сора киңәш.
Тукай аңлар ,иң мөһиме,
Татарча гынасөйләш.

**Диана:**

Туган телне яттан сөйләп
Үсеп җиткәнбез шулай.
Җирдә барлык балалар да
Ярата сине Тукай.
**Г.Илназ:**
Апрель җитсә, исемеңне
Җырына куша тургай.
Милләтемнең кояшы син,
И моңлы, нурлы Тукай!
**Аделя:**
Илдә – кояш, җирдә кояш.
Тукай көне канат җәйгән.
Бәйрәм бүген! Бәйрәм бүген!
Тукай көне – безнең бәйрәм.
**Җыр “Тукай абый” З.Туфайлова**

**Алып баручы.** Әйе, сөекле Тукаебызны без беркайчан да истән чыгармыйбыз. Аны яратабыз, зурлыйбыз. Шигырьләрен, әкиятләрен укып яшәргә өйрәнәбез.Ә хәзер 10 төркем кызлары башкаруында “Әпипә” бию карап китик.

**“Әпипә” биюе**

**Алып баручы.**Ә хәзер 8 нче төркемгә йөрүче Зәлинә белән Полина башкаруында Г.Тукайның “Бала белән күбәләк” шигыре.

**“Бала белән күбәләк” шигыре.**

**Алып баручы.** Менә, балалар, күбәләкләрне рәнҗетергә ярамый, аларның гомерләре бик кыска бит.

*(Ф. Яруллинның “Шүрәле” музыкасы астында залга Шүрәле керә.)*

**Шүрәле:** Исәнмесез, балалар. Сез мине таныдыгызмы?

**Балалар:** Әйе, син бит Шүрәле.

**Шүрәле:** Казан артындагы бер урманнан
Тукай мине табып танытты.
Бүген мине күпме кеше белә,
Күпме бала мине яратты.
Былтыр кысып китте бармагымны
Тик аңарга үпкәм юк күптән.
Үзем зарар салмак идем аңа,
Начар гамәл кылмам мин бүтән.
Балалар, минем уйныйсым килә, әйдәгез кети-кети уйныйбыз.

**Алып баручы:** Тукта әле, Шүрәле, бәйрәм вакытында нинди кети-кети уйнау ул. Балаларны тыңлап кара әле син, безнең балалар синең турында җыр беләләр.

**“Шүрәле” җыры.**

**Шүрәле:** Ай-яй бигрәк матур җырлыйлар. Карагыз әле, анда тагын кемдер килә, Былтыр булмасын тагы, мин качыйм.

**Алып баручы**. Курыкма, Шүрәле дус, Акбай ул, ул да бәйрәм икәнен ишетеп, шуңа килеп җиткәндер.

*(Мәтәлчек атып Акбай керә, аның артыннан малай)*

**Г.Тукай “Кызыклы шәкерт” шигыре.**

**Алып баручы**: Балалар, һәр нәрсәнең үз вакыты бар. Әйтәләр бит, “Калган эшкә кар ява”, – дип. Кечкенәдән өйрәнергә кирәк һәр эшкә, аннан соң булырга мөмкин. Ә безнең балалар һәр эшне вакытында башкара.

**Алып баручы**: Ә менә хәзер, Шүрәле, безгә уйнасак та була. Әйдә, Шүрәле, “Кети-кети” уенын уйнамыйбыз, ә безнең яраткан “Ачык авыз” уенын уйныйбыз.

**Шүрәле**: Әйдәгез, әйдә, мин дә бу уенны беләм! Бергәләп уйныйк!

***Уен “Ачык авыз”***

(Балалар аллы-артлы парлашып түгәрәк ясап басалар. Бер кеше парсыз кала. Ул уртада басып тора. Гармунчы бию көе уйный башлый. Шул вакытта эчке якта торган укучылар түгәрәк ясап җитәкләшәләр һәм бию көенә әйләнәләр. Шулай бераз әйләнгәннән соң, көй кинәт кенә туктала һәм

эчке яктагылар тышкы якта басып калган кешеләр белән парланалар. Бер кеше тагын парсыз кала. Шул кешегә җәза бирелә.)

**Алып баручы:** Шүрәлеләр яшәгәнгә
Ышанмый кемнәр генә.
Су анасы әкият сөйли
Серле җәй төннәрендә.

Әллә безне ишетеп Су анасы үзе дә килә инде?

*Су анасы керә. (Як-ягына карана, нидер эзли)*

**Шүрәле**: Әй, син, Су анасы! Ни эшлисен? Ни эзлисең анда? Кил бирегә. Утырыйк, сөйләшик бераз.
**Су анасы**: Юк, юк. Вакытым юк синең белән утырырга. Чәчләремне тарарга тарагымны эзлисем бар.
**Шүрәле**: Мин монда килгәндә бер тарак таптым. Синеке түгелме ул? *(Күрсәтә)*
**Су анасы**: Минем тарак, минем алтын тарак. Рәхмәт, Шүрәле. Ярар, киттем әле мин.
**Шүрәле:** Кая ашыгасын син, Су анасы?
**Су анасы**: Бәйрәмгә барасым бар.
**Шүрәле**: Ник монда да бәйрәм бит.
**Су анасы**: Ә ник алайса мин дөрес килдеммени? Тукай бәйрәменә эләктемме?
**Алып баручы**: Дөрес килдең, Су анасы, бик дөрес.
**Су анасы**: Рәхәтләнеп шигырьләр тыңлар идем мин алайса.
**Алып баручы**: Безнең балалар яраткан шагыйребезнең бик күп шигырләрен өйрәнделәр.Менә тыңлап карагыз әле..
**Су анасы**: Бик шатланып. Әйдә, Шүрәле, икәү бергә тыңлыйбыз.
*(Су анасы белән Шүрәле балаларның шигырьләрен тыңларга утырылар)*
**Алып баручы**: -5 төркемнән сезгә **“ Гали белән Кәҗә”** шигырен сөйләп китәр.
-6 төркемгә йөрүче Әминә, Альмир,Эмилия, Раил башкаруында **“Бу кайчак була?”**
-11 төркемгә йөрүче Җәүдәт башкаруында **“Кошларга”шигыре**
**-** Ә хәзер сезгә 7 нче торкем балалары **“Эш беткәч уйнарга ярый** “шигырен сәхнәләштереп күрсәтерләр**.**
-2 төркемгә йөрүче Әминә башкаруында **“Көз”**шигыре
-13 төркемгә йөрүче Кәрим белән Рәзилә башкаруында **“Бичара куян”**шигыре
-Гаилә – һәр кеше тормышында иң кадерлеседер, әлбәттә. Г. Тукай иҗатында гаилә бик зур урын алып тора. Безнең һәрберебезне дә кечкенә чакта әниләребез бишек җырлары җырлап йоклаткандыр. Ә хәзер сезнең игътибарга ” **10 нчы төркемгә** йөрүче **Зилә белән Азалия** Г. Тукай сүзләренә язылган **“Бишек җырын”** башкарып китәрләр.
**Су анасы:** Ай-яй Г.Тукайның бик күп шигырьләрен беләсез икән .Бик матур итеп сөйләдегез. Балалар, ә сезнең арада тапкырлар бармы? Сез табышмаклар яратасызмы?
**Балалар:** Әйе, яратабыз**.**
**Су анасы:** Алайса тыңлагыз. Табышмакларның җаваплары Г.Тукайның әсәрләре белән бәйле

1. Нәкъ кеше кебек үзе,
Бар маңгаенда мөгезе.
"Былтыр кысты” дип акыра,
Туганнарын чакыра. **(Шүрәле “Шүрәле” әкияте)**
2. Туннарга киендерә,
Җылыта, сөендерә,
Тоягы була ярык,
Исеме аның...... **(сарык, “Кәҗә белән сарык”)**
3. Лает, косточки грызёт,
Мяч поймает, принесёт!
Скачет радостно у ног,
Это маленький **( щенок, «Забавный ученик»)**
4. Сакаллы килеш туа.
Берәү дә гаҗәпләнми**.( кәҗә, "Гали белән кәҗә”)**
5.Чуар, йомшак күлмәге,
Тотсаң, уңа бизәге.
Тоттырмый ,китә очып ,

Я кала җирдә посып.**(күбәләк, "Бала белән Күбәләк”)**
6. Кто за стенкою шуршит,
Тонким голосом пищит,
Сыр от них не утаишь.
Всем ворам - воришка. **(мышь, «Мышь, попавшая в молоко»)**
**Шүрәле:** Бик зур рәхмәт. Миңа сезнең бәйрәмегез бик охшады. Мин күп шигырләр тыңладым, Туган телегезне яратасыз, Тукай абыегызны да онытмыйсыз икән.
**Су анасы**: Рәхмәт, балалар. Мин үземә файдалы әйбер алдым. Җәй көне су буена ял итергә килегез.
Шүрәле: Инде алайса безгә китәргә вакыт.
**Бергә:** Саубулыгыз!
(Балалар саубуллашалар.)
**Алып баручы**: Кадерле балалар, шуның белән Габдулла Тукайга багышланган бәйрәмебез ахырына якынлашты. Әйдәгез бу матур бәйрәмне бергәләп “Туган тел” җырын җырлап тәмамлыйбыз.
Барысы да басып “Туган тел” җырын җырлыйлар.
**Алып баручы**: Рәхмәт сиңа, бөек Тукаебыз. Без сине яратабыз. Шигырь, әкиятләреңне укып, яшәргә өйрәнәбез!